Республика Татарстан

Совет Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАРЫ

10.06.2022 ел Менделеевск ш. №113

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының тотрыклы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад, алгарышлы социаль икътисадый үсеш территорясе һәм эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары Л.Р. Әхмәтовның Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының тотрыклы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру турында мәгълүматын тыңлап, фикер алышканнан соң,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының тотрыклы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетына, шәһәр һәм авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыруның төп пунктларын гамәлгә ашыру буенча максатчан эш алып барырга, 2022 елга планлаштырылган күрсәткечләрне үтәүне тәэмин итәргә;

- халыкның тормыш сыйфатын күтәрүгә, инвестицияле җәлеп итүчәнлекне күтәрүгә һәм югары җитештерүчән эш урыннары булдыруга юнәлдерелгән эшне дәвам итәргә;

«Менделеевск» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенә (ТОСЭР) резидентлар җәлеп итү эшен активлаштырырга;

- район бюджетына физик һәм юридик затлардан салым түләүләренең һәм җыемнарның үз вакытында керүен тәэмин итү чараларын күрергә;

- кече һәм урта бизнесны активрак үстерергә, районның тулаем территориаль продуктында кече һәм урта эшкуарлык субъектларының өлешен арттыру буенча эш алып барырга;

- район муниципаль берәмлекләре территорияләрен социаль-икътисадый үстерүнең милли проектларын, республика программаларын сыйфатлы гамәлгә ашыру буенча нәтиҗәле чаралар күрергә, гражданнарга мәгълүмат бирү һәм милли проектлар кысаларындагы чараларга җәлеп итү эшен көчәйтергә;

- Менделеевск шәһәренең 55 еллыгына багышланган чаралар әзерләргә һәм югары дәрәҗәдә уздырырга.

- район территориясендә яшәүче халыкларның мәдәни үсеше, телләрен, гореф-гадәтләрен саклау өчен тигез шартлар тудыру буенча алга таба да эш алып барырга.

3. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ

- Менделеевск муниципаль районының белем бирү кластерын нәтиҗәле үстерү өчен шартлар тудыру эшен милли мәгарифкә һәм яшь буынны тәрбияләүгә аерым игътибар биреп, дәвам итәргә;

- иң яхшы белем бирү, педагогик һәм идарә практикалары үрнәкләрен ачыклау һәм аларны гамәлгә кертү буенча системалы эш алып барырга;

- химия предприятиеләре өчен квалификацияле кадрларны һөнәри әзерләүне һәм яңадан әзерләүне исәпкә алып, районда урта-махсус белем бирүне үстерү концепциясен эшләргә, шул исәптән Менделеевск химия-технология колледжын төзү буенча;

4. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МКУ

- сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру, даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче район халкының санын арттыру һәм халыкны массакүләм спортка җәлеп итү өчен уңай шартлар тудыру буенча эшне дәвам итәргә.

- Менделеевск муниципаль районында Спорт елына, шул исәптән “Геройлар узышы” федераль проектына багышлап, халыкның киң катламнарын җәлеп итеп, спорт чараларын оештыру һәм тиешле дәрәҗәдә уздыру.

5. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә тәкъдим итәргә

- игенчелектә һәм терлекчелектә алдынгы технологияләр кертү һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге соралмаган җирләрне әйләнешкә кертү чараларын дәвам итәргә;

- сөт терлекчелегендә җитештерү темпларын арттыруга һәм район авыл хуҗалыгы оешмаларында эре мөгезле терлекләр санын арттыруга юнәлдерелгән чаралар күрергә;

- Авыл халкының эшлекле активлыгын арттыруга, гаилә фермаларын һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә юнәлдерелгән эшне дәвам итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http:pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының профильле даими комитетларына йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары Л.К. Галеева